Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

2023 елның 10 ноябре № 109

Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Күл авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 27 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Күл авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Киндер Күл авылы, Клуб урамы, 20 б адресы буенча мәчет бинасында үткәрергә.

2. 2023 елның 27 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Күл авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Киндер Күл авылы, Клуб урамы, 20 б адресы буенча мәчет бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлегенең Киндеркүл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән һәм ялгыз аналардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә ашыгыч хәрби хезмәткә чакырылган затлар; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаиләләре әгъзалары; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хезмәткә контракт төзегән затлар һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан кала түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Зиратны ачу, Киндер Күл авылы зираты территориясен төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү;

- Киндер Күл авылында урам юллары челтәрен тоту, проект-смета документациясен эшләү;

-Киндер Күл авылында электр энергиясен саклаучы лампаларны, яктырткычларны, махсус җайланмаларны сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү,
- Киндер Күл авылы территориясен төзекләндерү;
- Киндер Күл авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза үткәрү.
- Насослар сатып алу һәм урнаштыру, Киндер Куль су манарасы коймасын эшләү, проект-смета документларын эшләү.
- Юлларны вак таш түшәү җайланмасы, вак таш өслекле юлларны ямау, Киндер Күл авылындагы торбаларны сатып алу һәм салу, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, янгын гидрантларын ремонтлау, Киндер Куль урамының янгын сүндерү гидрантларын комплектлау, проект-смета документациясен эшләү;
- Киндер Коль авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау (торбаларны алыштыру, материал, җиһазлар сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү.
-Урамнарны вак таш җәелгән юлларны ремонтлау, проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
-Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау, янәшәсендәге территорияне төзекләндерү, прокт-смета документациясе.

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы
урынбасары В.М.Ахатов